

ЛАЕШ КУРОРТЫ
Кама ярында кунакханә, кафе, рестораннар, яхта кую урыннары төзергә җыеналар

> 2

«МӘРХӘМӘТ»ЛЕ АРАЛАШУ
Депутатлар балаларга кагылышлы сорауларга җавап бирде

> 2

МӘХӘББӘТЛЕ ГАИЛӘ
Рөстәм Миңнехановка балан бәлешен татып карарга тәкъдим иткән

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – бирелә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 78 (29045) | Шимбә | 3 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

КҮЗЛӘР КҮККӘ ТӨБӘЛГӘН

Бүген авыл халкының кәефе чамалы чак. Республиканың төрле районнарына шалтыратып, хәл белешкәннән соң, әнә шундый нәтиҗәгә килдек. Дәррәү кубып печән әзерлисе урынга, күпчелек җирләрдә кешеләр, корылыктан кибеп беткән үләнгә карап, зар елый. Халык, хәзрәтләр җыелып, яңгыр сорап дога кылалар. Берничә генә районда яңгыр явып сөендергән. Анда яхшы уңыш җыеп алырга өметләнәләр.

yalkyn.ru

Мөслимнән Рушат Солтановның терлекләре күп түгел, кәҗәләр генә асрый. Ләкин печән темасы берничек тә битараф калдыра алмый, ди ул.

– Чыннан да, быел яз бик матур килде. Якты, кояшлы. Ләкин аңа карамастан, халыкның карашы күккә төбәлгән. Районда хәзрәтләр яңгыр сорау йоласын да башкарды инде. Бездә явым-төшем юк бит. Яз көне бөтенләй яңгыр ямады. Нәтиҗәдә бездә печән юк. Хәтта фермерларның күпьеллык үләннәре дә бик начар хәлдә. Икенче каты булмасмы, дип көтә инде халык. Беренче катка юк кына үләнне дә чабып куялар. Бакчадагы үлән дә чыкты да кипте. Терлек азыгы бәяләре артмасын иде, дип телибез. Авыл халкы үз продукциясен болай да түбән хакка сата. Шуңа күрә без әле дә шифалы яңгырлар явып, үләннең кабат күтәрелеп китүенә өметләнәбез, – диде ул.

Аның фикеренчә, халыкның малларны киметә башлау куркынычы зур.

– Халык мал асраудан нинди дә булса файда күрергә тиеш, – ди ул. – Тик хәзер файда урынына зыян килә. Шулай булгач, гомер буе терлек асраган абзыйлар да уйга калды. Тик мин бөтенләй үк төшенкелеккә бирелмәс идем, өмет бар әле.

Азнакай районы халкының да кәефе юк.

– Башка елларны без беренче кат печәнне Сабан туе алдыннан яки аннан соң ук чаба башлый идек. Тик быел үлән бөтенләй үсмәде. Башта кырау сукты. Люцерна да, болын печәне дә саргаеп бетте. Яңарып маташа үзе, ләкин яңгыр юк бит. Бу атна башында күрше авылдагы танышларыбыз чабып, әзерләп яталар иде, тик аларныкы да начар. Башка елларга караганда бик аз, – диде безгә фермер Илмир Гәрәфиев.

Аның фаразлавынча, болай булса, печән бәяләре дә кыйммәт булырга мөмкин. Илмир Гәрәфиев берничә авыл халкының сөтен дә җыя. Аның сүзләренчә, сөт бәяләре һаман шулай торса, терлек азыгын кыйммәт бәядән сатып алырга туры килсә, халык көзгә терлекләрен бетерә башлаячак.

– Авыл халкының телендә бер генә сүз: көзгә терлекләрен бетермәкчеләр. Бәяләр күтәрелмәсә, я киметәбез, я бетерәбез, диләр. Инде хәзердән үк сыерларын сатучылар бар. Үзебезнең авылда гына да шушы көннәрдә ике кеше сөтлебикәсен сатып җибәрде. Мал асрауның мәгънәсе юк, диләр. Аларга печән дә, ашлык та кирәкми хәзер. Әле маллар көтүгә йөргәнгә генә бераз җайлырак. Көзгә калдырмыйбыз, диләр. Файдасы булмагач, кешенең терлек асрау дәрте юк.

Ютазы районының Кәрәкәшле авылыннан Зөлфия Әхмәтҗанова да шундый фикердә торуын әйтте.

– Быел печән булмас ул, ашлык та кыйммәт булыр. Сөт хакы юк, авыл халкы барыбер дәшми дип, аны махсус төшерәләрме? Кеше сөйләп йөрмәячәк ул, сыерын гына бетереп куячак. Ә беткәч, аны кире торгызып булмый инде. Үзебез дә сыерны киметергә уйлап торабыз, – диде.

Апас районының Олы Бакырчы авылында яшәүче Миләүшә Булатова гаиләсе күпләп мал-туар асрый һәм башка еллардагы кебек быел да барлык терлек азыгын да сатып алырга уйлый.

– Печәнгә төшәргә иртә әле. Бәяләре турында да сөйләшкән кеше юк. Безнең якларда яңгыр яхшы ява. Корылык, дип әйтерлек түгел. Печән дә бик әйбәт, – диде Миләүшә ханым.

Кукмара районында да берничә авыл халкы гына печәнгә төшкән. Тик Бакчасарай авылында бераз сабыр итеп торалар әлегә.

– Халык ныклап торып печән әзерләргә Сабан туйлары узганнан соң гына тотыныр дип уйлыйм. Печән басуларын караштыргалап кайттык. Әллә ни сөенерлек түгел әле. Үлән юка күренә. Яңгырның рәхәтләнеп, бастырып яуганы юк бит. Безнең авылда мал-туар һәрвакыт күп булды, чөнки кешеләр терлек асрап көн иттеләр, төп табышны шуннан алдылар. Тик безнең авылда да терлек саны кими башлады. Быел көтүгә чыккан маллар буенча фикер йөртсәк, сарыклар күпкә азайган. Сыерлар да кимегән. Менә шунысы күңелсез, – диде Чулпан Һадиева.

Чирмешән районының Туймәт авылында яшәүче Рамил Кәримов та, әлегә халыкта печән кайгысы юк, дип белдерде. Бу якта да бар халык, зарыгып, яңгыр көтә.

– Бездә печән турында сөйләшкән кеше юк, чөнки иртә әле, – диде ул. – Яңгыр яумагач, үләне үсмәде. Аның нәрсәсен чабасың? Бар өмет – яңгырда.

Сан

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, **2** июньгә Татарстанда **24999** гектар мәйданда күпьеллык үлән чабып алынган, **74903** тонна сенаж әзерләнгән. Күпьеллык үлән әзерләү буенча Буа, Апас, Әтнә, Азнакай, Нурлат районнары алда бара. Иң күп сенаж исә әлегә Әтнә, Буа, Яшел Үзән, Апас районнарында әзерләнгән.

Августны көтәбез

Республикабызның 8 шәһәре һәм бер авылы яңа парк-скверлар булдыру өчен 670 миллион сум отарга мөмкин. Татарстан шәһәрләрен үстерү институты матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Бөтенроссия кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр бәйгесендә Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Минзәлә, Менделеевск, Тәтеш, Нурлат, Кукмара һәм Свияжск катнаша. Бәйге нәтиҗәләре быел август аенда мәгълүм булачак. Җиңгән очракта, инде киләсе елда ук Татарстанда яңа иҗтимагый киңлекләр барлыкка киләчәк.

Парк-скверлар проектларын архитекторлар, социолог-белгечләр, шәһәр оешмалары вәкилләре, район хакимиятләре эшләгән. Бу эшкә шулай ук шәһәр-авылларда яшәүчеләр үзләре дә җәлеп ителгән.

Проектлар җиңү яуласа, әйтик, Бөгелмәдә үсмерләрнең үз территориясе булачак. Нәтиҗәдә аларның ял итү мөмкинлекләре артачак.

Җыеп кына куясы

Илебездә модульле йортлар төзелеше үстереләчәк. Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин әйтүенчә, мондый технологияне үстерү яңа төбәкләребездә торак торгызуга бик нык ярдәм итә. «Анда безнең бер максат, ул да булса – кешеләрне подваллардан чыгару. Заводта эшләнгәнне төзелеш мәйданчыгына китереп җыясы гына кала. Мариупольдә торакның тиз төзелүе шуңа бәйле», – дигән ул.

Яңа төбәкләрдә модульле йортлар кору өчен материаллар Краснодар краеннан китерелә. Хәзерге вакытта бу төбәкләрдә 900 бина торгызылган инде. Быел тагын 80 йортта төзелеш эшләре тәгәлләнәчәк.

Министр билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта кәгазь эшен киметү, барлык документларны электронлаштыру буенча зур эш алып барыла. Аның әйтүенчә, төзелешне ярты елга тизләтү мөмкинлеге бирәчәк бу.

Без – өченче

Татарстан иң күп сандагы ИТ-компаниягә ия булган төбәкләр өчлегенә кергән. «Реальное время» басмасының аналитик хезмәте белгечләре Россиядә ИТ-базарны өйрәнеп, теркәлгән ИТ-компанияләр саны буенча 20 төбәкне билгеләгән.

Шулай итеп, ИТ-компанияләр Мәскәүдә барыннан да күбрәк санда теркәлгән (50,8 мең). Икенче урында – Санкт-Петербург (14,4 мең). Татарстан – өченче (7,8 мең).

Бүген республикабызда «айтишник»ларга 1321 вакансия тәкъдим ителсә, Мәскәүдә – 17 тапкыр күбрәк (22515). Әйтергә кирәк, вәгъдә ителүче хезмәт хаклары да күпкә аерыла: 20 меңнән 800 мең сумга кадәр.

Татарстан Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгында әйтелгәнчә, республиканың ИТ-базарына 5 меңгә якын кеше җитми. Технологик компанияләр генә түгел, бәлки «цифр»га күчкән күп кенә бизнеслар да мондый хезмәткәрләргә кытлык кичерә.

Безнең республикада программист иң кирәкле ИТ-белгечлек булып тора. Аларның хезмәт хакы – 15 меңнән 300 мең сумга кадәр.

Яңалык

Гаиләнеке «пачутта»

Россиядә гаилә ипотекасы алучылар саны арткан. Ел башыннан бирле илдә әлеге программа кысасында 19 меңнән артык килешү төзелгән. Бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 5 процентка күбрәк. 2021 ел белән чагыштырганда исә бу сан 8 тапкыр (!) арткан. Күптән түгел «ВТБ» банкы белгечләре шундый нәтиҗәгә килгән.

Белгечләр әлеге программаның популярлашуын аннан файдалана алучылар сафы киңәйтелүгә бәйләп аңлата. Билгеле булганча, быелдан башлап Россиядә гаилә ипотекасын рәсмиләштерү өчен шартлар яхшырды. Хәзер аны 18 яше тулмаган ике баласы булган һәр гаилә рәсмиләштерә ала. Балаларның кайсы елдан соң тууы мөһим түгел. Билгеле булганча, аңа кадәр ул 2018 елдан соң баласы туган гаиләләр өчен генә гамәлдә иде.

– Демографик вазгыятьне яхшырту – дәүләтебездәге өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Бу очракта гаилә ипотекасы гаиләнең яшәү сыйфатын яхшыртырга ярдәм итә, ил халкына кулай бәядән уңайлы торак алырга мөмкинлек тудыра. Аның бер генә түгел, ике балалы гаиләләргә дә бирелә башлавы әлеге программадан файдаланучылар санын бермә-бер арттырды, – ди «ВТБ» банкының вице-премьеры Евгений Дячкин.

Белгечләр уздырган тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, гаилә ипотекасын күбрәк 36 яшьләр тирәсендәге ир-атлар рәсмиләштерә. Быел май аенда теркәлгән ташламалы ипотеканың яртысыннан артыгы (54 процент) нәкъ менә шуларга туры килә.

Ил халкы арасында әле дә булса бер бүлмәле фатир популяр, ди белгечләр. Рәсмиләштерелгән барлык ипотека килешүләренең 39 проценты шундый торак алу өчен төзелгән. Гаилә ипотекасы программасы буенча ике бүлмәле (37 процент), өч бүлмәле фатир (22 процент) алучылар да шактый. Ил халкының 22 проценты ипотека рәсмиләштергәндә ана капиталын кулланган. Шуларның 18 проценты аны айлык түләүләрне каплап бару өчен тотса, калганнары ана капиталы акчасын беренчел кертем буларак файдаланган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сүз уңаеннан, май башында Россия Президенты Владимир Путин укытучылар өчен ташламалы ипотека булдырырга кушты. «Урта һөнәри белем бирү оешмаларында эшләгән педагогларга «Профессионалитет» федераль проекты кысасында ташламалы ипотека кредитлары бирү мәсьәләсен карарга», – диелә карарда.

Хәзерге вакытта Россиядә ташламалы ипотеканың берничә төре бар. Шул рәвешле ил халкы, гаилә ипотекасыннан тыш, авыл ипотекасы, хәрби ипотекадан да файдалана ала.

Сүзгә-сүз

Владислав ДАВАНКОВ, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары:

Депутат булып сайлануымны белгәч, улым өй эшләрен бетерү турында закон чыгаруны сорады. Мәскәүдә әти-әниләр белән очрашуда моңа вакыт җиткәнен аңладым. Өй эшеннән азат итү балалар һәм укытучылар файдасына булыр дип ышанам.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ИНТЕРНЕТ

83%	81%	4 сәгать 9 минут
интернетны бер тапкыр булса да куллана	интернетны көн саен куллана	кулланучының көн саен интернет киңлегендә уздырган уртача вакыты

«Россия интернет форумы – 2023» чарасында китерелгән мәгълүмат

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен; гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 1051 сум 80 тиен; гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Ялган хакында дөрес сүз

Ялганны без яратмыйбыз. Алдаган кешене кайчак күралмау чигенә җитәбез. «Әй, аның бит бер дөрес сүзе дә юк», – дибез ялганларга яраткан кеше хакында. Ләкин үзебез дә кирәк булганда алдашудан артык тартынмыйбыз. Кайбер психологлар белдерүенчә, кеше заты – гомумән, алдашу буенча чемпион. Интернет тулы фейклар, сәясәтчеләр, хәтта дәүләт җитәкчеләре күзен дә йоммый алдаша, ирләр хатыннарын «балыкка барам» дип алдый, хатыннар «бу алкам биш меңлек кенә» дип ирләре күзенә төтен җибәрә, үсмер – ата-анасына, хезмәткәр җитәкчегә төлке мае сөртергә читенсенми.

Хәтта табиблар белән дин әһелләре дә алдаша. Тик алар ялганы кайчак файдага да булырга мөмкин. Русча аны «ложь во благо» диләр. Ә менә ышанучан өлкәннәрне зур суммаларга төп башына утырткан әшәке җаннар – мошенниклар – үз файдасына тырыша. Гомумән, теләсә кайсы ялганның төбендә аның авторының шәхсән үзенә файда һәм җиңеллек эзләве ята. Кибетчеләрнең кибеткә кергән саен, күзгә карап, безне фәлән сумга «өтү»ен күп кеше хәтта алдашуга да санамый. Күнегелгән чөнки. Саный китсәң…

Без исәпкә дә алмаган алдашулар бар. Бөтенләй җенең сөймәгән кешегә елмаю – шулай ук ялган бит. Ул әле – икейөзлелек тә. Хөрмәт итмәгән кешегә кул бирү дә нәкъ шул. «Заманы шундый: эткә дә «җизни» дияргә кирәк», – ди бер танышым. Килешмим. Килешсәм, үзем дә ялганчы булам чөнки. «Эткә җизни дигәч, үзең кем буласың соң?» – дип әйтеп ташлаганымны сизми дә калам. Тик туры әйткән туганына ярамаган – танышым хәзер өч бармак белән генә исәнләшә. Исәпкә, санга алынмаган кырыкмаса-кырык төрле алдашуларга, мәсәлән, пластик хирургияне дә кертеп була. Җыерчыкларны яшереп, яшь, чибәр булып йөрүне. Тик андый операция үткән кеше үзе бер дә алай уйламый, үзен чыннан да яшәргәнгә саный, сөенә. Алдашканда гел шулай бит: кеше дигәнең үз алдашуына күз йома, ә үзен алдаганнарын яратмый. Бәндәдәге мин-минлек, эгоизмның янә дә бер чагылышы – «миңа ярый, башкаларга – юк» инде бу.

Көн саен күзебезгә, колагыбызга ябырылып торган реклама дигән мәгълүматта да дөреслек ташка үлчим генә. Реклама теләсә кайсы товарны тылсымлы үзлекләргә ия итә, күкләргә күтәрә. Ә пропаганда нәрсә? Анда да хакыйкать аз. Миллионнарга мәгълүмат чаралары аша ялган яудыру, аларны исертү, зомбилаштыру – үтә гөнаһлы гамәл. Әле тагын «Иң масштаблы алдашулар сугыш барганда, аудан соң һәм сайлаулар алдыннан күзәтелә» дигән сүз бар. Бу исемлеккә балыкчыларны да өстәп булыр иде. Миңа таныш ике балыкчының икесе дә бик теләп һәм яратып шыттыра. Алай кылану – аларга балык тоту кебек үк кызык шөгыль, параллель хобби. Сайлаулар дигәндә дә кызык. Иң демократик илләрдә дә иң югары постларга дәгъва итүче кандидатлар да, соңыннан үтиме, юкмы – мул итеп вәгъдәләр өләшә, сайлаучының колагына озын-озын токмачлар элә. Бу – сайлау технологиясенең аерылгысыз бер өлеше, шоу. Сугыш вакытларында да, заманына, дәүләтенә һич карамастан, каршы як югалтулары биш, хәтта ун тапкыр арттырылырга мөмкин, үзенеке шул чама киметелә. Имештер, беркайда да язылмаган шундый канун, традиция ярдәмендә, бәрелеш кайчан, кай тарафта гына бармасын, халыкның кәефе, ватанпәрвәрлеге, җиңү рухы тиешле югарылыкта тотыла. Алда әйтелгән «ложь во благо» булып чыга инде, алайга киткәч. Ә кемдер саннарга ышанмый икән, яндырылган танкларны, бәреп төшерелгән самолетларны үзе барып санап кайтсын, булдыра алса… Шунысы билгеле: чын саннар, чын мәгълүмат, гадәттә, канкоеш бетеп хәтсез еллар узгач кына калкып чыга.

Гавамның «бозылып» бетмәгән, күңелендә чисталык, ихласлык яшәгән беркатлырак катлавы да бар бит әле. Сабый кебек саф күңелле. Андыйлар сирәк алдаша. Шулар ук күбрәк корбан сыйфатында да кала. Тик аларны кызганмыйлар, киресенчә «лох» атамасы тагып, тилемсәгә, юләргә чыгаралар. Ягъни ихласлык, ышану, башкаларны да үзең кебек намуслы дип уйлау синдә бар, яши икән, син оттырасың. Андый сыйфатлар бәндәгә бер комачау, хәтта кимчелек булып чыга. Менә шундый кыек көзгеләр дөньясында яшәп ятыш бүген. Кайбер тарафларда хәтта дәүләт институтлары да катыргыдан. Аерым илләрдә парламент бар, тик ул парламент түгел. Чөнки ул башкарма хакимияткә буйсынган, аның сүзеннән чыкмый. Сайлауларның да, кайдадыр чыны булган кебек, ясалмасы, имитация кимәлендәгесе дә яшәп килә. Кем җиңәсе, ничә процент тавыш җыясы бер ел алдан билгеле сайлау сайлаумы инде ул?..

Алдашу адәми затка табигатьтән килә, дигән аклану яши. Аз-маз килешеп була. Тик кеше заты ялганны күп тапкыр камилләштермәде микән? Әйе, хамелеон, төсен үзе яшәгән тирәлеккә карап үзгәртмәсә, бик тиз кемнеңдер ризыгы була ала. Куян да «алдакчы»: җәен – соры, кышын – ак. Табигатьтә һәркем диярлек башка берәү өчен ризык булганлыктан, һәр төр исән калу, нәселен дәвам иттерү дигәндә маскировкадан да, башка күп төрле хикмәтләрдән дә баш тартмый. Үрмәкүчләр турында фильм бар. Анда «черная вдова» дигән, табигать кушкан вазыйфасын үтәү белән «сөйгәне»н тотып ашый торган ана үрмәкүч турында да күрсәтәләр. Баксаң, ата үрмәкүч һәрдаим ризык булмый икән. Ул кансыз «хатын»ын алдарга өйрәнгән. Ничек итеп, дисезме? «Йомыш» алдыннан ул пәрәвезгә чебен эләктерә, шуны шәпләп пәрәвез җебенә урый да ана бөҗәккә китереп бирә. Тегесе, ризыкка алданып, төргәкне сүткән арада, «ир» үз эшен башкара да тиз генә кача. Чебен эләкмәгән чакта да ата үрмәкүч аптырап калмый, пәрәвезгә эләккән берәр чүпне шәпләп төрә, ана үрмәкүч алдына китереп сала икән. Ставка хәйран зур шул: йә син, ялган кулланып, теләгеңне үтәп тә исән каласың, йә беркатлыланып, ризык буласың…

Ялган белән шактый мул сугарылган, фейклар, муляж, бутафория кулланган гаделсез дөнья турында, төптән уйлаганда, яхшы сүз әйтү авыр. Дөньябызның зур базар икәнлеге, кемнеңдер анда алдап, кемнәрнеңдер даими алданып яшәве хакында күп сөйләп була. Һәммәбездә дә бөртекне кибәктән аерып, аралап торучы фильтр булу, аның камил эшләп торуы кирәк. Гадилек, беркатлылык, наданлык яшәгәндә, ялганчылар һәрдаим булачак.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ



tatarstan.ru

Иң яхшысы – аларга. Китапханәсе дә, балалар бакчасы да, музыка мәктәбе дә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казанның Киров һәм Мәскәү районнарында социаль объектлар белән танышты.
Әйтик, Татарстан Рәисен «Ышаныч» психологик-педагогик ярдәм үзәге белән таныштырдылар. Ул катлаулы тормыш хәлендә калган 14–35 яшьлекләргә психологик яктан булышу өчен эшли.
Соңрак Рөстәм Миңнеханов 395 номерлы балалар бакчасы, 2 номерлы музыка мәктәбе, 27 номерлы китапханә эше белән танышты.

ХЕЗМӘТ ҺӘМ ХӨРМӘТ

Былтыргы нәтиҗәләр буенча республикада 700 мең тонна каучук, 13,7 млн шин, 1,7 млн тонна пластмасса җитештерелгән, 22,5 млн тонна углеводород чималы эшкәртелгән. Җитештерелгән химия һәм нефть химиясе продукциясенең гомуми күләме 1,8 трлн сумга бәяләнә. Бу узган елгы күрсәткечтән 20 процентка күбрәк. Казанышлар – тармакның 54 мең хезмәткәренең эш нәтиҗәсе. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Химиклар көне уңаеннан узган бәйрәмдә шул өлкәдә эшләүчеләрне котлады.

Рәис ассызыклаганча, Татарстан – илнең алдынгы химия һәм нефть химиясе үзәкләренең берсе. Республикадагы хезмәткәрләр, югары уку йортларында һәм тикшерү үзәкләрендә эшләүчеләрнең сәнәгать үсешенә зур өлеш кертүләрен дә билгеләп үтте ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстанда яңа технологияләр үсеше дә дәвам итә. Соңгы елларда гына да сәнәгый мөмкинлекләрне арттыру һәм яңарту өчен 100 млрд сум күләмдә акча җәлеп ителгән.

Быел «Казаноргсинтез» оешмасының барлыкка килүенә – 65 һәм беренче продукция җитештерә башлауга 60 ел тулды. Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, завод төзелеше республикадагы химия тармагы үсешенә зур этәргеч бирә.

– Ярты гасырдан артык тарихы дәвамында предприятие коллективы данлы хезмәт юлын үтте. Бүген мин тармак ветераннарына тирән рәхмәт һәм хөрмәт сүзләрен җиткерәм, – диде Рәис.

Ул шулай ук «СИБУР» компаниясе белән хезмәттәшлекне дә бәяләде:

– Компаниянең тәҗрибәсе безнең предприятиеләрнең базардагы урынын ныгытырга һәм Татарстанда химия һәм нефть химиясен алга таба үстерүгә яңа этәргеч ясарга мөмкинлек бирәчәк.

ӘКИЯТТӘ КУНАКТА

ЛАЕШТА ТИҢЕ БУЛМАГАН КУРОРТ ТӨЗИЛӘР

Туризм

Киләчәктә су буенда рәхәтләнеп ял итү өчен Татарстаннан читкә китеп тә торасы булмаячак. Республика Инвестицион советының чираттагы утырышында «Лаеш» курорты проекты турында сөйләделәр. Әйтүләренә караганда, чарада тәкъдим ителгән унбер проект арасында бу – иң кыйммәтлесе. Ял мәйданына 16 миллиард сумнан артык акча җәлеп итмәкчеләр. Лаешта безне ни көтә?

– Туризмны үстерүгә бәйле килешүне «Корпорация Туризм.РФ» белән моннан бер ел элек төзедек, – ди Татарстан туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов. – Бу – безнең өчен бик әһәмиятле проект. Ул туризмны үстерергә ярдәм итәчәк. Лаеш – Татарстан гына түгел, бөтен Урта Идел буе өчен тарту көченә әвереләчәк.

Курорт Лаеш шәһәреннән бераз читтәрәк, Чулман буенда урнашачак дип көтелә.

– «Лаеш» ял мәйданының төп исеме түгел, аңа яңа атама бирәчәкбез, – дип алдан ук кисәтеп куйды «Корпорация Туризм.РФ» генераль директорының беренче урынбасары Денис Секачев. – Халыктан моңа бәйле кызыклы тәкъдимнәр булса, аларны рәхәтләнеп карап тикшерәчәкбез. Бөтен Идел буенда иң кәттәсе булачак курортка исемне, бәлки, нәкъ менә сез уйлап табарсыз.

Шунысын да әйтик: ил күләмендә дә мондый проект тәүге тапкыр тәкъдим ителә. Барлыгы 73 гектарга якын мәйданда туристларга ел әйләнәсе ял итү өчен шартлар булдырырга җыеналар. Моның өчен өч һәм дүрт йолдызлы кунакханәләр, спа-үзәкләр, рестораннар, глэмпинг һәм яр буенда ял итү өчен инфраструктура төзеячәкләр дип фаразлана. Кунакханәләрдә яшәү өчен бүлмәләр саны гына да 1250дән артып китәчәк. Җәй көне су коенып чыккач, урман эко-сукмаклары буйлап йөрергә, балык тотарга мөмкин булса, кыш көне туристларга чаңгы, тимераяк, кар чанасында шуарга тәкъдим итмәкчеләр. Биредә үк сәүдә эшен җәелдерү дә каралган. Курортта 1,5 мең эш урыны барлыкка киләчәк икән.

Әлеге проектның үзенчәлеге шунда: Лаеш яр буен яхталар өчен махсус җиһазландырмакчылар. Су буйлап сәяхәт итәргә яратучылар биредә туктап ял итә, ремонт эшләрен башкара һәм җилкәнле судноларын кышлыкка калдырып тора алачак, ди. Бу уңайдан яхталар өчен озынлыгы 150 метр тәшкил иткән причал, җәй көне туктап тору өчен – 300, ә кышка 500 урын төземәкчеләр.

– Бу илдә соңгы утыз елда яхталар өчен башыннан алып ахырына кадәр җиһазландырылган тәүге шундый яр буе булачак. Ул барлык экологик таләпләргә җавап бирәчәк, – ди Денис Секачев.

Дөрес, әлегә булачак курорт кәгазьдә генә. Сүздән эшкә киләсе елда күчәргә җыеналар. Курортны 2027 ел башында кулланышка тапшырмакчылар. Проектны тәкъдим итүчеләр эшләре уңачагына да шикләнми. Географик яктан отышлы урында урнашкан Лаеш курортын Бөек Идел юлының мөһим транспорт челтәренә әверелдермәкчеләр.

– Бүген Бөек Идел юлы турында күп сөйлиләр. Ә Лаеш ул – галәм үзәге, Идел үзәге. Мәсәлән, Санкт-Петербургтан Лаешка кадәр теплоходта килеп, биредә ике-өч көн яшәргә һәм, очкычка утырып, илнең теләсә кайсы почмагына китәргә җайлы, – ди Денис Секачев.

Аның фикерен Сергей Иванов та хуплады.

– Туристлар Казанга очкычта килеп, Лаешта яхтага күчеп утыра һәм Идел буйлап сәяхәткә чыгып китә ала. Мәсәлән, Татарстан курортыннан Санкт-Петербургка кадәр алты-җиде көн йөзәргә кирәк, – дип үз фаразлары белән уртаклашты ул.

Хыялмы бу, әллә чынбарлыкмы – монысын вакыт күрсәтер. Төзелеп беткәч тә, Лаеш курортында елына 620 меңгә якын турист көтәләр әнә. Ял бәясе дә билгеле. Мәсәлән, бүген рәсемдә генә булган өч йолдызлы кунакханәдә бер төн кунып чыгу – 5–6 мең, дүрт йолдызлысында 15 мең сум торачак, ди. 2027 елга кадәр вакыт бар, әллә акча җыя башларгамы?

Эльвира ВӘЛИЕВА

8 июньгә билгеләнде

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышы 8 июньдә узачак. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде.

Депутатлар 24 мәсьәләне, шул исәптән 11 республика законы проектын, 2 федераль закон проектын һәм Россия субъектларының 2 закон инициативасын карап тикшерүне күздә тота.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, көн тәртибендәге мәсьәләләргә күчкәнче, гадәттәгечә, соңгы вакытларда республикада булган кайбер мөһим вакыйгаларны билгеләп үтте. Аерым алганда, үткән якшәмбедә Дәүләт Советына һәм җирле үзидарә хакимияте органнарына өстәмә сайлаулар узган. Чаллы шәһәре Электротехник округында Дәүләт Советы депутатларын сайлауда «Партия Роста» вәкиле Руслан Нигъмәтуллин иң күп тавыш җыйды. Җирле үзидарә депутатларын өстәмә сайлауда «Бердәм Россия» партиясе вәкилләре – 5 мандат, үзен үзе тәкъдим итүчеләр 2 мандат алуга ирешкән.

Фәрит Мөхәммәтшин Дәүләт Советының 7 закон инициативасына этәргеч бирү мәсьәләсенә аерым тукталып үтте. Алар – Россия парламентының түбәнге палатасында төрле стадияләрдә карап тикшерүдә. Исегезгә төшерәбез: республика эшләгән федераль закон проектлары күптән түгел генә Дәүләт Советы Рәисенең Дума Рәисе Вячеслав Володин белән очрашуында җентекләп каралды. «Кайбер тәкъдимнәребез авыррак уза, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Мәсәлән, наркотик матдәләрне законсыз җитештергән һәм саткан өчен судларның иң түбән чиктән дә йомшаграк җәза билгеләргә тиеш түгеллекләре турында бик кирәкле закон проекты. Шуңа да карамастан, федераль закон чыгаручылар, гамәлдәге законга каршы килмичә, безнең закон инициативасын хуплау турында уйланалар. Аны эшләп җиткерергә кирәк».

Дәүләт Советы Рәисе республика парламенты депутатларын, республиканың закон инициативаларын кабул итүне тизләтү өчен, Думаның профильле комитетлары рәисләре белән ныграк эшләргә чакырды.

Алда торучы утырышка килгәндә, анда 2022 елда республика бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын үтәү турында закон проектлары беренче укылышта карап тикшереләчәк.

Утырышның көн тәртибенә шулай ук Татарстан Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап кертелгән. Депутатлар утырышта яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру турында яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков чыгышын да тыңлаячак. «Хөкүмәт сәгате» кысасында транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов, ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Рөстәм Гарипов юлларда аварияләр санын киметү чаралары турында сөйләячәк.

Урыннар җитәме?

Кичә башкалада балаларны бакча һәм мәктәпләргә кабул итүгә бәйле «кайнар линия» эшләде. Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская Дәүләт Советындагы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт» оешмасы, төрле министрлык вәкилләре белән бергәләп әти-әниләрнең сорауларына җавап бирде.

«Безгә бакчада урын булырмы?» «Улым мәктәпне тәмамлады, кызым 1 нче сыйныфка бара. Абый-сеңел буларак, ул да шул уку йортына әләгә алырмы?» «Һөнәри уку йортларында бюджет урыннары күпме?» «Кайсы лагерьга барырга?» «Кайнар линия»гә килгән сораулар арасында төрлесе бар иде. Беренче сәгатьтә генә Казан, Чаллы, Әлмәт шәһәрләре, Чистай, Биектау, Кукмара районнарыннан 50 кеше шалтыраткан.

Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова белдергәнчә, белгечләр сорауларга җавап биреп кенә калмыйча, аны уку елы башланганчы хәл итәргә тырыша. Башка елларда, мәгариф оешмаларына гаризаны ничек тапшырырга, чиратны каян күзәтергә мөмкин, дип шалтыратсалар, бүген үзәктә – башка сораулар.

– Җәйге каникул башланды. Әти-әни баласын кайда да булса ял иттерү турында уйлый. 1–10 сыйныфларга, бакчага кабул итүгә бәйле сораулар да бар, – ди Татьяна Ларионова. – Республикада яңа уку елында 11 мәктәп ачылачак, 87 мәгариф оешмасына капиталь ремонт ясалачак. Бу инде – бөтенләй башка мөмкинлекләр дигән сүз. Авыл мәктәпләре буенча мөрәҗәгатьләр була иде. Бу сораулар хәзер – Рәис контролендә.

Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская әйтүенчә, «кайнар линия»гә бакчаларга кабул итүгә бәйле сораулар еш килә. Республикада яңа бакчалар төзелеп торса да, проблема кала бирә. Бигрәк тә яңа төзелгән микрорайоннарга, Питрәч районына кагыла бу. Проблеманы хәл итүнең бер юлы – яңа йортларның беренче катларында бакчалар ачу.

– Бүген мәктәпкәчә оешмаларга кабул итүнең икенче дулкыны башланды. «Бала кергәнме, юкмы?» – дип кызыксыналар. Инвалид балаларны лагерьларга урнаштыру буенча да шалтыраттылар. Андый сменалар Бөгелмәдә, Яшел Үзәндә бар. Бөгелмәгә кадәр барырга ераграк, әлбәттә. Шуңа күрә Казан тирәсендәге лагерьларда төркемнәр ачарга кирәк дигән фикергә килдек, – диде Сәрия Сабурская.

Белгечләр арасында Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү бүлеге башлыгы Йолдыз Хисамиева да бар иде. Аннан бакчалардагы чират турында сораштык.

– Республикада 1984 бакча исәпләнә. 20 меңнән артык буш урын бар. Үзләре теләгән бакчага эләкмәгән очракта әти-әниләр якын-тирәдәгесен сайлый ала. Әйтик, башкалада Киров, Мәскәү, Яңа Савин районнарында буш урыннар күп. Совет районының «Весна» комплексында бераз проблема бар. Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә проблемалар юк. Питрәч районының Көек, Царево бистәсендә урыннарга кытлык. Авылларда киресенчә, балалар җитми. Чиратлар санын әлегә төгәл әйтеп булмый. Ни өчен дигәндә, балаларны туплау 31 августка кадәр дәвам итәчәк, – диде Йолдыз Хисамиева.

Сәрия МИФТАХОВА

ИЛҺАМЛЫ БӘЙРӘМ

Икенче тапкыр тапшырылучы премиягә Татарстанның халык артистлары Флюра Сөләйманова, Фердинанд Сәлахов, Әсхәт Хисмәтов һәм Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәүдәт Гыйләҗев лаек булды. Легендар җырчы Флюра Сөләймановага мәртәбәле бүләкне 84 яше тулган көнне тапшырдылар. Калган лауреатларны кичә сәхнәдә тәбрикләделәр.

– Илһам абый гомере буе милләткә хезмәт итеп яшәде. Ул һәрвакытта да тамашачы белән аралашты, милләт һәм тел турындагы фикерләрен үтемле итеп җиткерә белде. Милләт дип, татар дип янды. Бу сыйфат барлык җырчыларга да хас түгел. Эшен, бөтен нәрсәсен калдырып, концерттан соң да халык белән очрашып сөйләшергә, аңлатырга, өмет бирергә вакыт таба иде, – диде тантанада Татарстанның Премьер-министр урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев.

Васил Шәйхразыев әйтүенчә, төрле төбәкләрдәге Сабан туйларында иң беренче булып Илһам абыйны, Әлфия апаны көткәннәр.

– Бергә килсәләр, анда яшәүче халык чын мәгънәсендә рәхмәт хисләре кичергән, үзләрен бәхетле хис иткәндер. Әлеге премияне булдыру – Илһам Шакиров исемен мәңгеләштерү һәм бүгенге җырчыларыбызга, яшьләргә өмет бирү дә ул. Татар халкы һәрвакыт җырлап яшәде. Халыкка моң, җыр аша тәрбия бирү Илһам абыйның төп эше иде, – диде Милли Шура рәисе.

«Татар-информ»/Салават Камалетдинов

«Илһам Шакиров – халкыбызга Ходайдан бирелгән бүләк». «Халык җырлавы» номинациясендә премия лауреаты Фәүдәт Гыйләҗев әнә шулай диде.

– Илһам Шакиров премиясенә лаек булу – минем өчен бик зур горурлык. Без аны мәктәптә укыган чаклардан тыңлап, яратып, сокланып үстек. Легендар шәхесебезнең җырлары, моңнары халык күңелендә мәңге яшәр дип уйлыйм. Татарстан җитәкчелегенә, Мәдәният министрлыгына, минем җырга зур бәя биргән комиссия әгъзаларына олы рәхмәтемне белдерәм, – диде Фәүдәт Гыйләҗев.

«Үзебез исән чакта онытмабыз». «Халык җырлавы» номинациясенең тагын бер премия лауреаты Әсхәт Хисмәт «Зәңгәр шәл» спектакленнән Шәкерт җырын башкарды.

– 1937 елда Кәрим Тинчурин кулга алынгач, «Зәңгәр шәл» спектакле сәхнәдән төшә. Тинчурин аклангач, 19 елдан соң Ширияздан Сарымсаков спектакльне яңартып куя. «Карурман» сәхнәсендәге Шәкерт җырын җырларга Казан консерваториясенең икенче курсында укучы Илһам абый Шакировны чакыра. Спектакль ай буе аншлаг белән бара. Ә Шәкерт җырын халкыбыз Илһам абыйдан көн саен икешәр тапкыр җырлата торган була. Илһам абый исемендәге бүләкне алуым белән мин бик бәхетле. Җитәкчеләргә һәм комиссия әгъзаларына чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм. Халкыбызга бик рәхмәт. Үзебез исән чакта Илһам абыйны онытмабыз дип уйлыйм, – диде Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәтов.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышын 2023 елның 8 июнендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 2 июне
№ 1972-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 422-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «2022 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 421-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 425-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 424-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» һәм «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 420-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 419-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 427-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» 423-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 426-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 390-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 428-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларының (карарлар нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану хакында.
14. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында.
15. Экологик хисаплылык тапшыру өлкәсендә таләпләрне камилләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында.
16. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
17. 2022 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап.
18. А.Н. Латышев турында.
19. «Республика Татарстан» газетасы баш мөхәррире вазыйфасына А.Е. Угаровны билгеләп кую турында.
20. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 145 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха Республикасы (Якутия) Дәүләт Собраниесе (Ил Төмән) закон чыгару инициативасы хакында.
21. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{10} статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмуртия Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы хакында.
22. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 353469-8 номерлы федераль закон проекты турында (кулланучыга товарларның (продукциянең) техник регламентларда билгеләнгән таләпләргә һәм (яисә) мәҗбүри таләпләргә туры килүе турында тапшырылган туры килү сертификатлары һәм теркәлгән декларацияләр реестрындагы язмага сылтама бирү хакында).
23. «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» Россия Федерациясе Законының 52 статьясына үзгәреш кертү хакында» 325561-8 номерлы федераль закон проекты турында (түләүле чаралар оештырганда мәдәният оешмалары ташламалар билгеләргә хокуклы аерым категория гражданнарның исемлеген тулыландыру өлешендә).
24. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләре торышы, аларның санын һәм алардан килгән зыяннарны киметү буенча өстәмә чаралар турында».

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 2 июне
№ 1973-VI ДС

БАЛАН БӘЛЕШЕ

Быелгы Шәҗәрә бәйрәменең финал ярышында иң күзгә ташланганы Ютазы районының Урыссу авылыннан килгән Абдурахмановлар гаиләсе булды бугай. Бигрәк тә Кавказ халыкларының милли киемнәре җәлеп итте тамашачыны. Киемнәре генә түгел, бию-җырлары да, үз-үзләрен тотышлары да. Татарстанга Кавказ халкының кайдан килеп чыгуын без соңрак, әлеге гаилә сәхнәдә чыгыш ясаганда белдек.

Безнең бабай – авар

– Нәселебез Дагыстан Республикасы Чародин районының гүзәл Косрода авылыннан башлана, – дип таныштырдылар алар үзләрен. – 1906 елда анда безнең Магомед бабабыз туа. Аның әтисе – Абдурахман, бабасы Сөләйман икәне билгеле. Бабабыз ямьле балачак, күңелле яшьлек елларын шунда уздыра. Өйләнә, тормыш иптәше белән өч балага гомер бүләк итә. Ләкин гаиләнең бәхете озакка бармый. 1942 елны ул үз теләге белән фронтка китә. Шул ук елның маенда Харьков өлкәсен азат итү өчен барган сугышларда контузия алып, әсирлеккә төшә. Репрессия корбаны буларак, безнең якларга җибәрелә. Без аның ничек килеп чыкканын да төгәл генә белмибез. Ул бик шәп балта остасы булган, бәлки, аны бу якларга эшче куллар җитешмәгәннән җибәргәннәрдер, дип кенә уйлыйбыз. Сөйләүләренчә, шундый очраклар тагын булгалаган. Архивны күтәреп караган идек, бөтен җирдә «не знает» дигән сүзләр язылган, чөнки ул русча да белмәгән, сорауларга да җавап бирә алмаган. Туган якларына кайту өметен югалткач, бабабыз Ютазы районында төпләнеп калырга карар кыла. Фәридә әбиебезгә гашыйк булып, гаилә коралар, бер-бер артлы биш балалары туа. Аларның берсе, иң өлкәне – безнең Әнвәр бабабыз. Ул – безнең зур, тату гаиләбездә иҗат династиясенә нигез салучы. Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Менә без дә, шушы традицияне дәвам итүче буларак, үз һөнәребезне мәдәният белән бәйләдек.

Мәдәният кешеләре

Чыннан да, сәхнә кешеләре икәнлекләре күренеп тора Абдурахмановларның. Җырларга да, биергә дә, сөйләргә дә бик оста алар. Ике милләтнең гореф-гадәтләрен бер иткәннәр. Бүген генә Кавказдан килеп төшкәннәр диярсең. Белгәннәрен халыкка да җиткереп яшиләр.

Бабалары Әнвәр гомере буена Иске Урыссу авылында мәдәният йортын җитәкли. Хәләл җефете Фәния дә үзенә охшый: үзешчән сәнгать конкурсларында күп тапкыр лауреат исемен яулый. Уллары Рамил – «Сердәш» ансамбленең солисты, республика конкурслары лауреаты, тагын бер уллары Раил, халыкара бәйгеләрдә җиңеп, «Болгар», «Сердәш», «Бәйрәм» ансамбльләрендә җырлый. Оныклары Рөстәм Ютазы районында мәдәният бүлеген җитәкли. Халыкара, Бөтенроссия, республика бәйгеләрендәге җиңүләрен санап бетерерлек түгел. Чиләгенә күрә капкачы, дигәннәре дә бик дөрестер, күрәсең. Рамилнең Минзиләсе, Раилнең Ләйсәне дә – сәхнә йолдызлары. Минзилә – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ЮНЕСКОның бию буенча халыкара советы әгъзасы, «Ютазы йолдызлары» дип аталган бию ансамблен дә ул җитәкли. Ләйсән исә – спорт гимнастикасы буенча спорт мастеры, күп тапкырлар Россия чемпионы, педагог-хореограф. Рөстәмнең хәләл җефете Айгөл исә – район мәдәният йортында методист, җырчы да, биюче дә. Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтик: гаиләне туплап, шушы зур бәйрәмне оештыручы да ул. Өч яшьлек уллары Айдан да чын Кавказ егете булып җитешкән. Республика Рәисе белән дә кул биреп исәнләште. Хәзер менә шушы составтагы бер гаиләнең сәхнәне дер селкетүен, мөгаен, күз алдына китерә алгансыздыр дип уйлыйм.

Ядкәр

Шәҗәрә бәйрәмендә гадәттә төрле истәлекләр, ядкәрләр белән таныштыралар. Айгөл белән без бу хакта да сөйләштек.

– Гаиләгә кагылышлы истәлекләрне һәркем үзенчә саклый, – диде ул. – Берәүләр фотосурәтләр җыя, икенчеләре балачак хатирәләрен барлый, кайбер гаиләләрдә әби-бабаларының киемнәреннән, бизәнү әйберләреннән коллекция туплыйлар. Әйтергә кирәк, аларны бүген дә бик яратып тагып йөриләр әле. Абдурахмановларның гаилә ядкәре ул – папаха. Ир-атларга буыннан-буынга тапшырылып килә. Бабабыз Магомедка аны әтисе бүләк иткән булган. Гаилә традицияләре дигәндә, без әйберләрне генә күздә тотмыйбыз, әлбәттә. Ул – буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләр дә булырга мөмкин бит. Мәсәлән, балан бәлешеннән башка безнең йортта кунак өстәле әзерләнгәне юк. Аның үз сере бар. Әбиебез Фәридә бабабыз Магомедны балан бәлеше белән сыйлый торган була. Шулай итеп, ул сөйгән ярының йөрәгенә юл тапкан, күрәсең. Шуннан бирле балан бәлеше рецепты гаиләбездә буыннан-буынга күчеп, йортыбызга килен булып төшкән һәр хатын-кызга тапшырыла. Заманында Фәридә әбиебез аны килене Фәния әбигә өйрәткән, аннан әнием Минзилә отып алган. Хәзер исә балан бәлешен мин үзем дә бик тәмле итеп пешерәм. Фестивальдә оештырылган күргәзмәләр белән танышып йөргәндә, Рөстәм Нургалиевичка да балан бәлешен татып карарга тәкъдим иттек. Йөзебезгә тап төшәрлек булмагандыр дип уйлыйм.

Ерак ара якынайды

Ютазыда яшәүче Абдурахмановлар инде күптән Кавказдагы туганнары белән аралашып яшиләр. Табышырга интернет, социаль челтәрләр ярдәм иткән.

– Хәзер инде Дагыстандагы туганнарыбыз да безгә кунакка кайталар, үзебез дә барабыз. Авар халкының милли ризыкларын да пешерергә өйрәттеләр. Шуңа күрә мәҗлесләр үткәргәндә, табыныбызда хинкал, чәкчәк белән бахух (Дагыстан хәлвәсе) беррәттән торалар. Гаиләбез татар һәм авар халык ашларын бертигез хөрмәт итә, – ди Айгөл.

Гаилә шәҗәрәсен Айгөлнең әнисе Минзилә ханым төзегән. Бүгенгә җиде буын, 122 гаилә әгъзасы билгеле. Мәдәният кешеләре буларак, гомуми эш стажы – 150 ел.

Абдурахмановлар күргәзмәсендә бер күренеш бигрәк тә йөрәгемә уелып калды.

Фотосурәтләр куелган стендны күзәткәндә, күзләремә кара кием кигән бер ханымның моңсу карашы төбәлде. «Бу кем?» – дип сорамыйча түзә алмадым.

– Бу – Магомед бабабызның Дагыстанда өч бала белән калган беренче хатыны. Без аның фотосын йортыбыз диварына да элеп куйдык. Кадерле истәлек итеп саклыйбыз. Ике яктагы мәрхүмнәрнең дә җаннары тыныч булсын дип, догадан калдырмыйбыз, – диделәр алар. Ә бу тарихны Айгөл миңа соңрак сөйләде.

Бабасының туган якларын бик күрәсе килә. Рөхсәт бирелгәч, ул түзми, кайтып килергә уйлый. Озаклагач, әбисе Фәридә, олы улы Әнвәрне җитәкләп, кечерәкләрен әти-әнисендә калдырып, ирен эзләп китә. Таба. Анданиләр булганын Айгөл белеп бетерми. Әмма әбисенең: «Аның хатыны, балаларын җитәкләп, безне кара киемнән юл чатында озатып калды. Үзәкләрне өзәрлек бу күренеш гомерем буена мине озата барды», – дигән сүзләре бүгенгә кадәр килеп ирешкән.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Зур Шыя урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Баймурзина** Лидия Ивановна, Казан шәһәре Идел буе районының «173 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Гыйбадуллин** Рөстәм Гыйниятулла улы, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары **Закирова** Минзәлия Заһри кызы, Казан шәһәре Яңа Савин районының «146 номерлы «Ресурс» лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Кәримова** Диларә Салих кызы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) оештыру-кадрлар бүлеге башлыгы **Галкина** Наталья Эдуардовна, Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) техник бүлеге башлыгы **Чернов** Владимир Львович; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Гафиятуллина** Фәния Шәфикъ кызы; җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Казан «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте электр энергиясе производствосының техник газлар производствосы техник газлар производствосы буенча һава бүлү участогы аппаратчысы **Карпов** Александр Григорьевич, «1 нче районара юл-төзелеш идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте йөктөягеч машинисты **Нәкыйпов** Мөдәрис Габдрафыйк улы, «СУГАЗ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шакиров** Әбугали Рафоат улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «БУААГРОПРОМСНАБ» МАТДИ-ТЕХНИК ТӘЭМИНАТ БАЗАСЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сибгатуллин** Әнсар Мансур улы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Таҗетдинова** Фәния Җәүдәт кызы, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе **Яхин** Рәис Рәшит улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Түбән Кама шин» гавами акционер җәмгыятенең әзерлек цехы башлыгы урынбасары **Биккиниев** Марат Рушад улына, «Түбән Кама йөк машиналары шин заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең вулканлаштыру цехы пресслаучы-вулканлаштыручысы **Зарипова** Гөлнара Рашат кызына, «Кама» фәнни-техник үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сынау үзәгенең сынау лабораториясе инженер-технологы **Патрикеев** Евгений Борисовичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте нефть эшкәртү заводының эшләтеп җибәрү-көйләү эшләре буенча төркеме (күкертле нефтьләрне крекинглау җайланмасын (гидрокрекинг) эшләтеп җибәрү-көйләү эшләре буенча – 2) әйдәүче инженер-технологы **Тимофеев** Василий Александровичка, «ТАИФ-НК» акционер җәмгыяте нефть эшкәртү заводының үзәк завод лабораториясе башлыгы **Урманова** Маргарита Михайловнага, «Түбән Кама йөк машиналары шин заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җыю цехы резин эшләнмәләр һәм аяк киемнәре җитештерү җиһазларын көйләүчесе **Вәлиуллина** Елена Николаевнага, «Түбән Кама йөк машиналары шин заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әзерлек цехы транспортировщигы **Галәлиев** Рафис Риза улына, «Кама» фәнни-техник үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сынау үзәгенең химия лабораториясе химик анализ лаборанты **Кутукова** Елена Дамир кызына, Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводының әйдәүче инженер-технологы **Носов** Валерий Николаевичка, «Түбән Кама йөк машиналары шин заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең вулканлаштыру цехы вулканлаштыручысы **Сәгыйтов** Роберт Әмир улына, Казанның «Органик синтез» гавами акционер җәмгыяте баш инженеры хезмәте ремонтлау производствосының механика юнәлеше башлыгы **Харитонов** Виталий Андреевичка, «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционер җәмгыяте» акционер җәмгыятенең маркетинг, продукция җитештерү һәм сату идарәсе башлыгы **Газизуллина** Гөлнара Максут кызына, «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционер җәмгыяте» акционер җәмгыятенең 101-11 цехы ингредиентлар авырлыгы исемлеген төзүчесе **Галимова** Зөлфия Сәет кызына, «Аммоний» акционер җәмгыяте контроль-үлчәү приборлары һәм автоматлар цехының аммиак селитрасы производствосына хезмәт күрсәтү буенча контроль-үлчәү приборлары һәм автоматлар буенча слесаре **Егоров** Андрей Робертовичка, «Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы» акционер җәмгыятенең 110 номерлы цехы ярымсульфит тозлар җитештерү участогының смена мастеры **Немтырева** Светлана Анатольевнага, «Аммоний» акционер җәмгыятенең биологик чистарту корылмалары цехы хлоратор җайланмасы операторы **Шакирова** Илсөяр Хаҗинур кызына **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Мәхәббәт өчпочмагы

– Кем белән исәнләштең син әле генә?
– Катлауландырма инде, матурым. Әле аңа да синең кем икәнлегеңне аңлатасым бар.

* * *

Экстрасенслар, гадәттә, ирне кайтарырга вәгъдә итә. Хатынны кайтарырга вәгъдә иткән экстрасенсларны белмим. Димәк, хатынны кайтарыр өчен бер генә экстрасенсның да көче җитми.

* * *

Әгәр дә син ошатып йөргән ир-егет сиңа борылып та карамый икән, аннан әҗәткә акча алып тор: гел сине уйлап йөреячәк.

* * *

Яшь барган саен, күз күрүем бозыла. Шуңа күрә кияүгә чыгарга бер сәбәп тә күрмим.

* * *

Арыслан бары тик бер генә нәрсәдән курка – хатыныннан. Әгәр син дә хатыныңнан куркасың икән, димәк, син – арыслан.

* * *

Ул мине кире кайтарыр өчен бөтен көчен куйды: ике тапкыр миңа «ВКонтакте»да язды.

* * *

– Шундый каты сагындым сине...
– Соң, әйдә, очрашабыз.
– Ул дәрәҗәдә үк каты түгел инде.

* * *

Әгәр ул сиңа «минем синең белән җитди сөйләшәсем бар» дип яза икән, «минем дә синең белән җитди сөйләшәсем бар» дип җавап кайтар. Ул да борчылсын.

КАРА ЮМОР

– Куркыныч әкият сөйлим сиңа хәзер.
– Әйдәле.
– Урманда ике вегетариан адаша...
– Соң?
– Ахырда шуларның берсе генә вегетариан булып кала.

* * *

– Доктор, мин исән калачакмынмы?
– Без барыбыз да үләчәкбез.
– Алайса, мин ни өчен сезгә акча түлим?

* * *

– Сүндер әле шул «фильм ужасов» дигәнеңне. Әйдә, яңалыклар карыйбыз.

* * *

– Доктор, ботокс кадатсам, яшьрәк күренәчәкменме?
– Юк. Ботокс кадаткан яшьтәшләрең кебек күренәчәксең.

* * *

Хастаханәдә:
– Сулагыз! Сулагыз! Үлә күрмәгез! Сез минем бөтен диссертация эшемне бозачаксыз!

Фельетон

КЫРЫС ОСТА

– Сәлам! – диде сантехникка охшаган каратутлы абзый кеше. – Чакырдыңмы?

– Әйе. Ванна бүлмәсендә торба тишелде, – дидем мин, аның өс киемен салдырып.

– Торба ачкычы бармы? – дип кычкырды ул бераздан. – Шунсыз эш хөрти...

– Табабыз аны! – дидем мин һәм җәһәт кенә хуҗалык товарлары кибетенә чаптым.

– Бәлки, башта, подвалга төшеп, суны ябаргадыр?.. – дидем мин кыюсыз гына, кибеттән кайтып, ачкычны кулына тоттыргач. – Астагыларны су басуы ихтимал...

– Өйрәтмә! Бик белдекле булгач, үзең эшлиләр аны...

– Мин сантехник түгел. Кибернетика буенча...

– Юк-барга бөтенесе оста, ә торба акса, сантехник кирәк! Академикка да, профессорга да...

Сүзен әйтеп бетермәде, икебезне дә су фонтаны бәреп екты.

– Нигә катып калдың, бар, суны яп! – дип кычкырды ул. – Күрмисеңмени?

Әфган җиле бөтереп алгандай, аска, подвалга төшеп киттем.

Мин менгәндә инде су икенче катка ага иде.

– Кешеләр турында уйламыйсың. Кара бу торбаңны – череп беткән! – дип, ул краны белән бергә сынып чыккан торба кисәген аяк астыма ташлады. – Бишенче катка кунаклап алгансың да тыныч кына яши бирәсең. Ә астагыларны су басса да ярыймы?!

– Алыштырмыйлар бит. Өченче ел тиешләр иде...

Слесарь, өметен өзгәндәй, кулын селтәп куйды:

– Тиешләр, тиешләр... Берәр агач кисәге тап! Торбага бөке кагып куярга кирәк.

Күршеләрдән пычкы алып чыгып, идән щеткасы сабыннан кисеп алып, кулына тоттырдым. Ул аны пычак белән очларга кушты. Очладым. Чүпрәк сорады – бирдем. Чүкеч сорады – табып китердем. Ул, бөкене чүпрәк белән чолгап, торбага кагып куйды.

– Килеп чыкмасмы?

– Тимерчыбык белән борсак, ышанычлырак була инде, әлбәттә. Бармы?

– Табабыз аны! – дип, кызым укыган мәктәп ишегалдына чыгып йөгердем. Кичә генә металл ватыклары җыйганнар иде. Алып кайттым.

– Нәкъ үзе! Ярты метр чамасы кис. Тимер кисә торган пычкың бармы?

– Табабыз аны! – дидем мин һәм бер мастерскойга чыгып йөгердем. Тимер-томыр белән эш итәләр, анда булмый калмас.

– Менә булды! – дип елмайды ул, бөкене тимерчыбык белән борып куйгач. – Ярты дюймлы һәм дүрттән өч дюймлы вентильләр кирәк булыр. Аңладыңмы?

– Үзегездә юкмыни? – дип сорадым, гаепле кеше сыман, кыяр-кыймас кына.

– Булганы да юк, буласы да...

– Тукта, язып алыйм әле, йә бутармын. Болар белән эш төшкәне юк...

– Тагын ярты дюймлы һәм дүрттән өч дюймлы икешәр отвод кирәк булыр. Язып куй!

– Ничек табарга соң боларны?

– Сусыз утырасың килмәсә – табарсың! Шуларны тапкач, шалтыратырсың.

Анда йөгердем, монда чаптым, кушкан нәрсәләрен барыбер юнәттем дә шалтыраттым.

– Тиз юнәткәнсең. Кайберәүләр айлар буе эзли, – дип гаҗәпләнде ул.

Ул, килеп, нигәдер унитаз юдыргычын урыныннан ала башлады. Бу юлы мин гаҗәпләндем:

– Анысын ник аласыз? Шунсыз гына булмыймы?

– Күрмисеңмени, вентиль куярга комачаулый. Минем эшкә тыгылма, нишләргә икәнен үзем беләм. Син лутчы менә монда кара! – Слесарь борыным астына юеш кепкасын китереп тыкты. – Мах-мы-ыр минем. Хәтта куллар калтырый. И-их, бу укымышлылар... Бер дә белмиләр тормыш рәтен!..

Ничек кермисең кеше хәленә! Кибеткә йөгердем. Алып кайттым. Бик күңеле булды. Хәтта бертуганым сыман елмаеп куйды. Шундук, табын әзерләргә кушып, кемгәдер шалтыратып та алды:

– Монда эшләр тәртиптә. Көтәм, элдер әйдә!

Күп тә үтмәде, ишек шакыдылар.

– Исәнмесез! Эшләр ничек? Клиентның зары юкмы? – дип сөйләнә-сөйләнә, эшләпәле бер агай килеп керде.

– Авария бетерелде, клиент риза, – диде аңа слесарь. – Тукай әйтмешли, эш беткәч, уйнарга ярый: хәзер башны төзәтергә дә була... Йә, хуҗа, өстәлең әзерме?

– Әзер, әзер! Кулларыгызны юыгыз да утырышыгыз!

Ашадылар-эчтеләр. Бераздан җырлап та җибәрделәр:

Ишегалдым яшел чирәм,
Казлар йөри биешеп...
Сагынасыңмы, дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул!

Күңел биреп җырладылар. Хәтта күзгә яшьләр чыкты! Шулай җырлашып утыргач, оста нигәдер ванна бүлмәсенә кереп китте. Бераздан мине дә чакырып алды.

– Язып куй: бачокка яңа шланг кирәк. Тапкач, шалтыратырсың. Без аны шундук... Монысы кыскарак...

Ни әйтергә белмичә, катып калдым: унитаз юдыргычы ванна өстенә куелган! «Нигә?» дип сорамакчы идем, кыюлыгым җитмәде – күтәренке кәефләре кырылыр дип уйладым.

Әхәт САФИУЛЛИН

«Үпкәсез туй»

ФИДАРИС МОРТАЗИН АЛЫП БАРГАН СӘЕР ТУЙ

Фидарис Мортазин тамадалык эшенә моннан 15 еллар элек керешә. Очраклы гына килеп чыга бу. Бер мәҗлестә ул тавыш куючы дустына аппаратура ташырга булыша. Чарага алданрак килә. «Әйдә, җырла, син матур җырлыйсың бит», – ди моңа дусты. Фидарис «Эх, алмагачлары»н сузып җибәрә. Шулчак кунак апаларның берсе моның кесәсенә бер мең сум акча салган. Фидарисның төзелештә эшләп йөргән чагы бу. Көн буе зур йөк күтәреп эшләгән өчен – 450 сум. Ә монда 3 минутлык «алмагачлары» өчен – 1 мең сум! Шул көннән егет мәҗлесләрдә чыгыш ясауның тәмен белеп ала. Башта җырлый, аннары алып бару эшенә дә алына. Әмма бар да матур гына булмый шул. Төрле туйлар бар. Сәер мәҗлесләрнең берсе турында Фидарис «Ха-ха-ханә»гә сөйләде. Тантана башланырга тора. Кияүнең күзләре кара янган, кулы гипсланган. Бер-бер артлы кияүнең дуслары да җыела башлый. Кайсы трикодан, кайсы сланцыдан, берсенең йөзе кара янган, икенчесе гипстан. «Кемнәр соң бу?» – дип сорый Фидарис. «Бу – минем дусларым, берсе дә өйләнмәгән, шуңа кызларсыз», – ди кияү. Баксаң, булачак гаилә башлыгы шушы арада гына төрмәдән чыккан икән. Дуслары да шуның иш. Кыскасы, туй бик үк күңелле узмый. Бераз вакыттан кияүнең дуслары күрше өстәлгә алма, әфлисун кабыклары ыргыта башлый, сугыш-талаш чыга. «Командабыз белән бу туйны көчкә ерып чыктык та тизрәк таю ягын карадык. Бүген искә алырга кызык, әмма ул чакта бик үк күңелле булмады», – ди Фидарис.

Мач әйткән!



Оскар УАЛЬД, Ирланд драматургы:

– Үзең булып кал. Башка рольләр инде – башкаларда.

Кино, кино, киная

Без балачактан ятлап бетергән совет киноларында кайвакыт сәер хәлләр була. «Киноляп» диләр аларны русча. Татарча ничек атыйк? Сез уйлый торыгыз, ә без иң кызыклы сәерлекләрне барлыйк. Ә кем белә, бәлки, алар махсус эшләнелгәндер? Ярты гасыр узгач, «Ха-ха-ханә»дә телгә алыныр өчен? Бәлки, автор шулай күргән? Ә, мөмкин ки, бу – берәр кинаядер? Безгә нидер читләтеп әйтергә теләгәннәрдер?

Шурик эткә азык ташлый. Эченә дүрт таблетка тыга. Киләсе кадрда исә 5 таблетка күрәбез. Ә ни өчен Шурик кыз янына кунакка барганда йоклата торган дару алган – анысын үзе беләдер инде.

«Любовь и голуби» фильмы бик матур җирдә төшерелгән. Хәтта могҗизалы дияр идем. Күрегез: Митя дәдәй артындагы елга өстендә томан бер мизгелдә пәйда була һәм шундук югала.

Бу кадрлар кайсы фильмнан икәнен әйтеп тормыйбыз. Үзегез дә беләсез. Шкафның тоткасы тиз арада кая югалган соң? Әллә Ипполит урлаганмы?

Хәтерлисездер, йоклый торган капчыкка Шурик аяк киемен салып керә. Шул капчык белән тау елгасында шактый гына ага. Һәм кабат героебызның аягына карагыз. Шурикның ботинкасы!



Очлы күзәтүләр

✓ Һәр кешенең шундый хезмәттәше була: ул ялга киткәч, бөтен коллектив ял итә.
✓ 40 яшьтән соң өйләнми йөргән егет ул шыгрым тулы автобустагы буш урын сыман. Нәрсәседер дөрес түгел.
✓ Яшьлек тәмамлангач, косметичка әкренләп аптечкага әйләнә башлый.
✓ Иң шәп кардиотренировка – хезмәт хакы алгач, кибеткә чабу.

Әз-мәз мәзәк

– Туган көнне арзан гына кайда билгеләп узарга икән?
– Карандаш белән календарьда.

* * *

– Кызым, энеңне балалар бакчасына кертеп чыга алмассың микән? 100 сум бирер идем.
– Әни, апага биргәнче миңа гына бир, бакчага үзем керәм.

* * *

Мин Казанның шундый кәттә җирендә яшим: монда хәтта этләр дә миннән кыйммәтлерәк киенгән.

* * *

– Билгесез рәссамның бу картинасы 300 мең сум тора.
– Гаҗәп. Минем картиналарым 300 мең сум торса, мин билгесез булып йөрмәс идем.

Фотомәзәк

Дизайнерның фикер сөреше аңлашылды.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 278

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+